**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 август № 575

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 ел, 10 март, 202 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 ел, 10 март, 202 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 13 октябрь, 852 нче; 2013 ел, 18 март, 176 нчы; 2013 ел, 31 октябрь, 829 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 257 нче; 2014 ел, 10 июль, 481 нче; 2015 ел, 21 гыйнвар, 25 нче; 2016 ел, 26 июль, 508 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5 бүлекнең 5.2 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«башлык урынбасарлары, структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен эшчәнлек нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре исемлеген боерыгы белән раслый;

Баш ветеринария идарәсенә беркетелгән вазыйфалар процессларын (ярдәмче процессларын) үтәү стандартларын боерыгы белән раслый һәм аларның үтәлешен тәэмин итә;

Нәтиҗәлелекнең төп күрсәткечләренә ирешү нәтиҗәләре нигезендә башлык урынбасарлары, структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында нигезләмәне, шулай ук эшчәнлек нәтиҗәлелегенең

төп ирешелгән күрсәткечләренә бәйле рәвештә стимуллаштыручы түләүләр күләмен исәпләү тәртибен билгеләү хакындагы нигезләмәне боерыгы белән раслый;

Баш ветеринария идарәсе өчен билгеләнгән төп нәтиҗәлелек күрсәткечләре һәм хезмәт законнары нигезендә ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләре белән контрактлар (хезмәт шартнамәләренә өстәмә килешүләр) төзи.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков